ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«25» 02 2026 ел** **№ 50**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач муниципаль район Башлыгы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Куныр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча Куныр авыл җирлеге халкы катнашында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;
- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;
- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы Р. С. Фатыйхов;
- «ФПД РТ» ДБУ вәкиле.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын билгеләргә - кызыксынучы затларга аларны уздыру турында хәбәр итү вакытыннан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан артык була алмый.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәрнамә әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль район Башлыгы Р. Р. Нотфуллин